**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ КАРАРЫ**
**(V чакырылыш)**

**дүртенче утырыш**
**КАРАРЫ**

10 декабрь 25 ел № 18 Теләче ав.

2026 елга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның Фараз планын (Программасын) раслау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында"2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон, Теләче муниципаль районы Советының 2011 елның 11 июлендәге 53 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмә нигезендә, МКУ «Теләче муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» 2025 елның 28 ноябрендәге 369 номерлы хатын караганнан соң, Теләче муниципаль район Советы:

1. Әлеге карарга кушымта буенча 2026 елга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планын расларга.
2. МКУ «Теләче муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» на 2026 елга Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның расланган фараз планын үтәүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Район башлыгы А.Г. Фәтхуллин

Теләче муниципаль районы Советының 10.12.2025 елның № 18 карарына кушымта

2026 елга Теләче муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның ФАРАЗ ПЛАНЫ

I бүлек. Мөлкәтне хосусыйлаштыру өлкәсендә төп юнәлешләр

Теләче муниципаль районының 2026 елга муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) гамәлгә ашыруның төп максаты (алга таба - хосусыйлаштыру программасы) муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру.

2026 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Теләче муниципаль районының 2011 елның 11 июлендәге 53 номерлы карары белән расланган «Теләче муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмә (03.09.2014 №221, 13.11.2017 №110 үзгәрешләр белән) нигезендә гамәлгә ашырылачак.

1. 2026 елда мөлкәтне хосусыйлаштыру бурычлары.

Чираттагы елда мөлкәтне хосусыйлаштыру бурычлары булып тора:

- муниципаль мөлкәт белән нәтиҗәле идарә итү нигезендә район бюджеты керемнәрен арттыру;

- икътисадый үсешне тәэмин итү, җир һәм башка күчемсез милек базарын үстерү, предприятиеләрнең рентабельле һәм тотрыклы эшләвенә ирешү максатларында милек структурасын оптимальләштерү;

- муниципаль милек объектларының максималь санын граждан әйләнешенә җәлеп итү;

- хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итү.

2. Район икътисадында , шул исәптән икътисадның конкрет тармакларында (идарә өлкәләрендә) хосусыйлаштыруның структур үзгәрешләргә йогынтысы фаразы.

2026 елда хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль мөлкәт объектлары Исемлегенә районның муниципаль милкендәге объектлар кертелгән.

2026 елда муниципаль унитар предприятиеләрне, муниципаль милектәге акционер җәмгыятьләрнең акцияләрен хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

Гомумән алганда, 2026 елга Теләче районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планында (программасында) күрсәтелгән мөлкәт объектларын хосусыйлаштыру район икътисадында, шул исәптән икътисадның конкрет тармакларында (идарә итү өлкәләрендә) структур үзгәрешләргә йогынты ясамаячак.

3. Хосусыйлаштыруның Фараз планы гамәлдә булган 2026 елда хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт исемлеге Теләче муниципаль районы Советы карарлары нигезендә яңа күчемсез объектлар белән тулыландырылырга мөмкин.

II бүлек.

1. 2026 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез мөлкәт исемлеге

| № т/б | Күчемсез объект исеме | Урнашу урыны (адресы) | Гомуми мәйдан (кв.метр) |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәп бинасы, кадастр номеры 16:40:060301:93, җир участогы белән, кадастр номеры 16:40:060301:136, мәйданы 1385 кв.м. | ТР, Теләче муниципаль районы, Кече Мирәтәк авылы, Пушкин ур., 11А й. | 139 |
| 2 | Мәктәп бинасы, кадастр номеры 16:40:050201:158, җир участогы белән, кадастр номеры 16:40:050201:64 | ТР, Теләче муниципаль районы, Олы Саурыш авылы, Мәктәп ур., 24 й. | 61,2 |
| 3 | Балалар бакчасы бинасы, кадастр номеры 16:40:050101:162, җир участогы белән, кадастр номеры 16:40:050101:7, мәйданы 1659 кв.м. | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Олы Мишә авыл җирлеге, Олы Мишә ав., Парк ур., 3 й. | 353,3 |
| 4 | Тәмте-Мәтәскә БГББ бинасы, кадастр номеры 16:40:040401:117, җир участогы белән, кадастр номеры 16:40:040401:12, мәйданы 1880 кв.м. | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Тәмте-Мәтәскә авылы, Подгорная урамы, 18 йорт | 84,7 |
| 5 | Торак булмаган «Авыл мәдәният йорты» бинасы, кадастр номеры 16:40:070201:602, җир участогы белән, кадастр номеры 16:40:070201:175, мәйданы 1555 кв.м. | Татарстан Республикасы, Теләче муниципаль районы, Максабаш авылы, Татарстан урамы, 27 А йорт | 375,1 |

2. 2026 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчмә мөлкәт исемлеге

| № т/б | Күчемсез объект исеме | Саны, данә |
|---|---|---|
| 1 | Автотранспорт чаралары һәм җиһазлар | 5 бер. |